**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 декабрь 2023 ел № 214

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Куәм авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, 2023 елның 12 декабрендә узган тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Куәм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 15.12.2021 № 93 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Куәм авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең график һәм текст материалларының эчтәлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- “Шәхси торак төзелеше зонасы (Ж1) № 1-1” (реестр номеры 16:10-7. 71) территориаль зона чикләрен үзгәртергә;
- “Рекреацион билгеләнеш зонасы (Р2) № 1-3” (реестр номеры 16:10-7. 75) территориаль зона чикләрен үзгәртергә;
- “Күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зона (ОД) № 1-4” территориаль зонасы чикләрен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Куәм авыл җирлегенә территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Куәм авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы Рәисе Г.Г. Хәкимов